**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
**11 сентябрь, 2023 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№31-06**

**Актаныш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына генераль план булмау турында карар кабул ителгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктларның чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 08 августындагы 21-01 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уставы, Актаныш муниципаль районы Советы, РФ һәм ТР Юстиция министрлыгы идарәсе тарафыннан 2012 елның 11 сентябрендә теркәлгән Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына нигезләнеп,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Советының 2022 елның 08 августындагы 21-01 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертүне Зөбәер авылы, Түке авыл җирлеге, Илчебай авылы, Шәрип авылы, Уразай авыл җирлеге, Кәзкәй авылы, Тыңламас авылы, Кәзкәй авыл җирлеге, Татар Суыксу авылы, Мари-Суыксу авылы, Карт авылы, Татар-Суыксу авыл җирлеге, Яңа Җияш авылы, Иске Богады авыл җирлеге, Киров исемендәге совхоз поселогы, Киров авыл җирлеге, Иске Әлем авылы, Яңа Әлем авыл җирлеге чикләре турында мәгълүмат белән тулыландыру өлешендә расларга.
2. Әлеге карарны «Актаныш таннары» район газетасында, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны инфраструктура үсеше буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.И.Гариповка йөкләргә.

Актаныш муниципаль районы
Советы рәисе — Л.Р.Зарипов